Дүртенче чакырылыш ТР Питрәч муниципаль районы
Советының унбишенче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

9 сентябрь, 2021 ел № 98

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында бюджет процессы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2019 елның 24 октябрендәге 217 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында бюджет процессы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5 статьяның 9 пунктындагы 6 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- Россия Федерациясе керемнәре чыганаклары исемлегенә һәм бюджет керемнәре чыганаклары реестрына кертү өчен аларга беркетелгән керемнәр чыганаклары турында белешмәләр тапшыра;».

1.2. 34 статьяның 2 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«2. Район бюджеты проектын төзү түбәндәгеләргә нигезләнә:

- Россия Федерациясе Президентының Россия Федерациясе Федераль Собраниесенә Юлламасының Россия Федерациясендә бюджет сәясәтен (бюджет сәясәтенә таләпләр) билгели торган нигезләмәләре турында;

- Россия Федерациясе Милли үсеш максатларын һәм аларга ирешү буенча ачык хакимият органнары эшчәнлегенең юнәлешләрен билгели торган документлар турында;

- Россия Федерациясе Бюджет, салым һәм таможня-тариф сәясәтенең төп юнәлешләре (Татарстан Республикасы бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләре, муниципаль берәмлекнең бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләре);

- социаль - икътисадый үсеш фаразы турында;

- озак сроклы чорга бюджет фаразы (бюджет фаразы проекты, бюджет фаразына үзгәрешләр кертү проекты) турында;

- муниципаль программаларда (муниципаль программалар проектларында, күрсәтелгән программаларга үзгәрешләр проектларында).».

1.3. 51 статьяның 2 пунктында «максатчан билгеләнештәге субсидияләрне, субвенцияләрне, башка бюджетара трансфертларны бирү максатларында» сүзләрен «күрсәтелгән чараларны бирүнең тиешле максатларына» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарның 1.1 пункты рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә

3. Әлеге карарның 1.2 пункты, рәсми басылып чыккан көненнән бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта, 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның 1.3 пункты нигезләмәләре 2020 елның 31 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Питрәч муниципаль районы башлыгы И.М. Кашапов